| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.01.2022 Казан ш. № 6-1/кс-2022

Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендәге кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән бирелә торган кайнар суга 2022 ел өчен тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендәге кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән (алга таба – «Татэнерго» АҖ) бирелә торган кайнар суга, шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» АҖ Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

3. Билгеләргә:

әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла;

әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.01.2022 № 6-1/кс-2022 карарына кушымта

## Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендәге кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» АҖ бирелә торган кайнар суга 2022 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы | Ел | Җылылык саклау компонен-ты, сум/куб.м. | Җылылык энергиясе компоненты | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Бер ставкалы, сум/Гкал | Ике ставкалы | |
| | | | | | Егәрлек өчен ставка, аена мең сум/1 Гкал/сәг. | Җылылык энергиясе өчен ставка, сум/Гкал |
| 1 | «Татэнерго» АҖ* | | | | | |
| 1.1 | Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре | | | | | |
| 1.1.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә)** | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 26,77 | 1989,68 | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 26,77 | 2172,54 | - | - |
| 1.1.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 22,31 | 1658,07 | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 22,31 | 1810,45 | - | - |

<*> «Татэнерго» АҖ өчен җылылык саклау матдәсенә җылылык саклау матдәсенә булган компонентларны исәпкә алып кулланыла торган тарифлар Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга, җылылык белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык саклау матдәсенә 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 17.12.2018 №5-89/тэ карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 №5-31/тэ, 04.12.2020 №343-53/тэ-2020, 07.12.2021 №452-92/тэ-2021 карарлары редакциясендә) нигезендә билгеләнгән.
<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге